ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**28.12.2022**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 3591**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 02 ноябрендәге 2747 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районы физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 20 июнендәге 587 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2021 елның 02 ноябрендәге 2747 номерлы карары белән (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 13 гыйнварындагы 28 номерлы карарына кертелгән үзгәрешләр белән) расланган, Зеленодольск муниципаль районы физик культура һәм спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә, кушымта нигезендә, үзгәрешләр кертергә.
2. Учреждение җитәкчеләренә үз локаль актларын әлеге kararга туры китерергә.
3. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль район Советы Аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә буенча бүлегенә «Интернет» челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru ) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр составындагы Зеленодольск муниципаль районы рәсми порталында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В.Старостин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты 2022 елның 28
декабрендәге 3591 номерлы карарына
кушымта

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы физик культура һәм спорт муниципаль оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2021 елның 02 ноябрендәге 2747 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы физик культура һәм спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәдәге үзгәрешләр:

1.1. VIII бүлекнең 5 һәм 6 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр физик культура һәм спорт муниципаль оешмасы җитәкчесенә, эшчәнлегенең эффективлык критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, физик культура һәм спорт муниципаль оешмаларын гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

Физик культура һәм спорт муниципаль оешмасы җитәкчесенә стимуллаштыру характерындагы түләүләр ай саен, квартал саен, бер ел эшләү нәтиҗәләре буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәгән өчен гамәлгә ашырылырга мөмкин.

6. Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен физик культура һәм спорт муниципаль оешманың җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерына стимуллаштыру характерындагы түләүләр, аларның эшчәнлегенең эффективлык критерийлары нигезендә билгеләнгән эшчәнлек нәтиҗәләрен исәпкә алып, физик культура һәм спорт муниципаль оешмасы җитәкчесе тарафыннан билгеләнә. Җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерга стимуллаштыру характерындагы түләүләр ай саен, квартал саен, ел йомгаклары буенча, мөһим һәм аеруча мөһим биремнәрне үтәү өчен гамәлгә ашырылырга мөмкин".